Әлмәт шәһәре Башкарма комитеты
КАРАРЫ

«19» июль 2019 ел № 70

Капиталь төзелеш объектларын төзү,
реконструкцияләүнең иң чик
параметрларыннан баш тартуга
рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен тәэмин итү һәм планировка структурасы элементларын аерып чыгару максатларында, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 366 номерлы карары белән расланган беркетмә, Әлмәт шәһәре башлыгының «Гавами тыңлауларны билгеләү турында» 2019 елның 14 маендагы 19 номерлы карары , 2019 елның 14 июнендәге 4499 номерлы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре нигезендә ( «Альметьевский вестник»газетасы, 2019 елның 4 июлендәге 28 номер) , «Арслан»җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте мөрәҗәгате нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. «Арслан» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, 8 Март урамы, з/у 16 адресы буенча урнашкан 16:45:020110:39 кадастр номеры булган җир участогында капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләүнең чикләнгән параметрларыннан читләштерергә рөхсәт бирүне сорап мөрәҗәгать итәргә:

- участокның алгы чигеннән корылмаларның минималь чигенүе-1,9 м;
- участокның Ян чикләреннән минималь чигенү – 5,9 м, 9,15 м;
- участокның арткы чигеннән корылмаларның минималь чигенүе-16 м .

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары А. А. Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев